КАРАР

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Чурататыр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«14» ноябрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2019 елның 10 ноябрендә узган: «Сез, 2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылы территориясендә яшәүче, I төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1500 (мең биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

1) Зиратны тәртипкә китерү” мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 40 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 28 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 28 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез, 2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылы территориясендә яшәүче, I төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1500 (мең биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

1) Зиратны тәртипкә китерү” мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыены рәисе: А.А. Насыйбуллин

Әмзә авыл җирлеге башлыгы А.А. Насыйбуллин